ТИМГЕЛЛЕ АВЫРУ

Татарстанда кызамык белән авыручылар арта

> 2

ҮЗЕБЕЗНЕКЕ ТАТЛЫРАК

Татар бал кортының саннарын ишәйтмәкчеләр

> 2

ХАТЛАРДА – ЙӨРӘК ЖЫЛЫСЫ

Укучыларыбыз кадерле истәлекләре белән уртаклаша

> 3

##ҺӘРВАКЫТ ӘЗЕР!

Марат Әхмәтвәлиев, кешеләргә ярдәм итеп, тормышта ямь таба

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 47 (29014) | Сишәмбе | 4 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

СОЛДАТ ШУЛПАСЫ

Эльвира ВӘЛИЕВА

Язгы чакырылыш – 2023

1 апрельдән илдә армиягә язгы чакырылыш башланды. Хәрби хезмәткә чакыру, гадәттәгечә, 15 июльгә кадәр дәвам итәчәк. Мәгълүм вакыйгалар аркасында, сораулар да юк түгел. Хәрби хезмәткә алынган солдатлар кайда хезмәт итәчәк? Бу юлы армиягә чакыру кәгазен интернет аша гына җибәрәчәкләр дигән хәбәр дөресме? Язгы чакырылышка бәйле сорауларга ачыклык кертергә тырыштык.

vk.tatarstan.ru

– Улымның хәрби комиссариатка чакыру кәгазе – кулында, – ди Казанда яшәүче Гөлфинә Исламова. – Быел техникум тәмамлый. Укыган вакытта ук хәрби комиссариатка барып йөрделәр. «Повестка»ны шунда биргәннәр. Медицина тикшерүе узды инде, хәрби хезмәткә яраклы. Армиягә үзе, барам, ди. Курсташлары белән әнә шулай хәл иткәннәр. Ике улыбызны да кечкенәдән үк ир-ат хәрби хезмәт юлын узарга тиеш дип үстердек. Абыйсы армиядә булып кайтты инде. Аның солдат шулпасын эчкәнен сизмичә дә калдык. Тик бүгенге заманда хәрби хезмәтнең бер көне үзе бер елга тиң. Әлегә бу турыда уйламаска тырышам.

Бу язда Россиядә 147 мең, шул исәптән, Татарстаннан 3 мең чамасы егет солдат каешын буачак дип көтелә. Армиягә чакырылучыларның яше һәм хезмәт итү вакыты шул ук. Солдатка 18–27 яшьлек егетләр китәчәк. Алар бер ел хезмәт итәчәк. Сүз уңаеннан, быелгы язгы чакырылыш иске кагыйдәләр буенча узучы соңгы кампания булырга да бик мөмкин. Армиядә хезмәт итү яшен арттыруга бәйле яңа закон проекты киләсе елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк дип көтелә. Билгеле булганча, егетләрне солдатка хәзерге кебек 18 яшьтән алып 27гә кадәр түгел, ә 21 яшьтән 30 яшькә кадәр чакыра башламакчылар. Дөрес, үзләре теләк белдерүчеләрне 18 яшьтән дә солдатка алачаклар.

Хәрбиләр әти-әниләрне тынычландыра: егетләрне махсус операция барган урынга җибәрмәячәкләр.

– Россия Хәрби Көчләренең Генераль штабы белдерүенә нигезләнеп, язгы чакырылыш барышында солдатка алынучыларның барысы да Россия Федерациясе территориясендәге хәрби бүлекчәләрнең даими урнашу урыннарында хәрби хезмәт узачак. Ватан алдындагы бурычын үтәгәннәрне исә үз вакытында өйләренә кайтарып җибәрәчәкләр, – дигән Татарстан хәрби комиссары, генерал-майор Сергей Погодин «Татар-информ» агентлыгына.

Армиягә бару вакытын кичектереп тору хокукына ия булучылар исемлегендә, алдагы еллардагы кебек үк, студентлар, ялгыз әтиләр, өч яшькә кадәр инвалид бала тәрбияләүчеләр, дәүләт органнарында эшләүчеләр бар. Узган елның мартында әлеге исемлеккә IT компанияләр белгечләрен дә өстәделәр. Яңалык 27 яше тулмаган, оешмада кимендә бер ел эшләүче югары белемле хезмәткәрләргә кагыла.

Ә менә көллият-техникум бетереп, укуын югары уку йортында дәвам иттерергә теләүчеләргә ташлама юк.

– «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы федераль закон нигезендә һөнәри белем алганда армиягә бару вакытын кичектереп тору хокукын бер тапкыр гына бирү каралган. Шул рәвешле, моңарчы техникумда укыганлыктан, армия хезмәте кичектерелгән егетләргә вузга керү өчен кабат «отсрочка» бирелмәячәк. Мондый студентлар югары уку йорты эскәмиясеннән хәрби хезмәткә чакырылачак, – ди Сергей Погодин.

Язгы чакырылыш башланганчы ук, быел «повестка»ны интернет аша гына җибәрәчәкләр икән, дигән хәбәрләр таралды. Электрон чакыру кәгазьләре турында беренчеләрдән булып РФ Хәрби Көчләре Генераль штабының идарә башлыгы Владимир Цимлянский әйтте. «Әлеге эшнең нәтиҗәлелеген исәпкә алып, язгы чакырылыш вакытында ил күләмендә хәрби комиссариат вәкилләренә чакыру кәгазьләрен электрон рәвештә җибәрү бурычы куелды. Моның өчен техник мөмкинлекләр булмаса, «повестка»лар кулдан-кулга тапшырылачак», – диде ул. Кызган табага Россия Дәүләт Думасының Оборона буенча комитеты җитәкчесе урынбасары Юрий Швыткин да май өстәде. Аның әйтүенчә, «Госуслуги» порталы аша килгән чакыру кәгазе, хокукый яктан аны кулга тапшыру белән бер үк дәрәҗәдә булып саналачак. Ә компьютерда яки кесә телефонында Дәүләт хезмәтләре порталын бетереп ташларга теләүчеләр армия хезмәтеннән качучыларга тиңләштереләчәк.

Ахыры 2 нче биттә >

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы «Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты» бүлегендә язгы чакырылышка бәйле **8-(843)-221-60-06 «кайнар линия»**се эшли. Шалтыратуларны көн саен иртәнге сәгать уннан алып көндезге сәгать уникегә кадәр кабул итәләр.

Очрашу урыны – Казан

Киләсе елда Казанда БРИКС саммиты үткәреләчәк. Президент Владимир Путин Указында әйтелгәнчә, әлеге мөһим чара Россиянең оешмадагы рәислеге кысасында уздырыла.

«2024 елда БРИКС дәүләтләре башлыкларының очрашу урыны итеп Казан шәһәрен билгеләргә», – диелә хокукый мәгълүматлар рәсми сайтындагы документта.

Дәүләт башлыгы шулай ук оештыру комитетын булдыру бурычын куйган. Ул Россиянең оешмадагы рәислеген тәэмин итү белән шөгыльләнәчәк. Комитет рәисе итеп Россия Президенты ярдәмчесе Юрий Ушаков билгеләнгән. Указда әйтелгәнчә, комитет составы бер ай эчендә расланачак.

БРИКС Россия, Бразилия, Һиндстан, Кытай һәм Көньяк Африка Республикасын (КАР) берләштерә. Быел оешма саммиты КАРда уза. Әлеге чара берничә ел элек Екатеринбургта һәм Уфада да оештырылды.

Фонд ярдәм итәчәк

Президент Владимир Путин махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү фонды оештыру турындагы Указны имзалады.

Документта әйтелгәнчә, хәрби хезмәткәрләрнең һәм гаиләләре әгъзаларының лаеклы тормышта яшәвен, актив эшчәнлеген булдыру өчен «Ватанны саклаучылар» дәүләт фонды оештырыла. Яңа оешма адреслы, шулай ук социаль, медицина, психологик ярдәм күрсәтәчәк, шифаханә-курортларда сәламәтлекне ныгыту, тернәкләндерү мәсьәләләрен хәл итәчәк. Фонд 2014 елдан бирле Донбасста хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга да булышачак. Аның Күзәтчелек советы рәисе итеп Россия Президенты администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Кириенко билгеләнгән.

Кирәкле белгечләр

Татарстанда IT өлкәдәге белгечлекләрнең популярлыгын арттыруга юнәлдерелгән программа расланды. Премьер-министр Алексей Песошин тиешле боерыкны имзалады.

Программага берничә пункт кергән. Болар: 2022–2023 елларда Татарстан вузларында кабул итү кампаниясенә анализ ясау, бу мәгълүматларны яшьләргә җиткерү, IT өлкәдә чемпионатлар, VR-экскурсияләр уздыру һ.б.

Чараларга нәтиҗә ясап, әлеге юнәлештә кабул итү кампаниясен көчәйтү һәм 2025 елда IT белгечлекләр буенча белем алучылар санын арттыру күздә тотыла. Шулай ук максатчан юлламалар буенча укытуга квоталарны арттыру планлаштырыла.

Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин программаны тормышка ашыруга җаваплы итеп билгеләнгән.

Мөмкинлекләр ярминкәсе

14–15 апрельдә Татарстанның барлык шәһәрләрендә «Россиядә эш. Мөмкинлекләр чоры» илкүләм эшкә урнаштыру ярминкәсенең беренче этабы узачак. Казанда ул Ленин исемендәге мәдәният йортында үткәрелә.

Әлеге чараның максаты – тиз генә эш табу белән беррәттән, карьераны планлаштыруга да ярдәм итү. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәренә караганда, анда вакансияләр белән генә түгел, бәлки заманча мәшгульлек хезмәтенең барлык мөмкинлекләре белән таныштырачаклар.

Эш бирүчеләр арасында «Казан вертолет заводы», «Элекон заводы», «Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе», «Горбунов исемендәге Казан авиация заводы», Дары заводы, Карпов исемендәге химия заводы, КамАЗ, «Ремдизель» кебек оешмалар булачак.

Ярминкәнең икенче этабы июньгә планлаштырылган. Аңа эш бирүчеләр, шулай ук белгечләр җәлеп ителәчәк. Алар студентларны һәм ата-аналарын – эшкә урнашу өчен кулай тармаклар, ә һөнәр сайлаучыларны иң кирәкле юнәлешләр белән таныштырачак. Сүз уңаеннан, ярминкәдә югары хезмәт хакы белән эш урыннары: аерым алганда, «Элекон» заводына инженер-конструктор (хезмәт хакы 150 мең сумнан башлана), «АР СИ ЭР» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә программа белән идарә ителешле станоклар көйләүче вазыйфасы (хезмәт хакы 120–150 мең сум) тәкъдим ителәчәк.

Чарада катнашу буенча тәфсиллерәк мәгълүматларны 8(843) 277-40-09 телефоны аша алырга мөмкин.

Белеп тор!

Бармак бөгеп саныйсы юк

Өчесе, бишесе һәм сигезе. Илдә балаларга түләнә торган пособиеләр өчен бердәм түләү көннәре билгеләгәннәр. Бу хакта Россия Социаль фонды хәбәр итә.

Яңалык әти-әниләр рәсмиләштергән түләүләрнең күбесенә кагылачак дип фаразлана. Аерым алганда, алга таба бер яшькә кадәр бала белән өйдә утыручыларга пособие һәр айның сигезендә килә башлаячак. «Яңалык апрельдән үк гамәлгә керә. Бу айда акча узган ай өчен киләчәк. Сигезе бәйрәмгә туры килгән очракта, пособие алдагы эш көнендә күчереләчәк», – дип ачыклык керткәннәр Социаль фондта.

Быел июньнән өч яшькә кадәрге балага ана капиталыннан айлык түләү һәр айның бишесендә килә башлаячак. Тәүге тапкыр яңа тәртип май пособиесенә кагылачак. Ягъни июньдә узган ай өчен акча исәпләячәкләр. Хәзер исә ана капиталыннан акча күчерү көннәре ил төбәкләренә карап аерыла. Аны айның беренче яртысында да, ай азагында да түләргә мөмкиннәр. Шуңа күрә айныкын айга исәп-хисап ясала. Рәсми мәгълүматларга караганда, илдә 280 мең гаилә өч яшькә кадәрге балага ана капиталыннан айлык түләү рәсмиләштергән. Әлеге төр пособие айлык керемнәре төбәктә җан башына ике яшәү минимумыннан кимрәк булган гаиләләргә түләнә. Хезмәт хакларыннан тыш, пенсия, премия, «больничный» кебек түләүләр дә исәпкә алына. Айлык түләү күләме төбәктә баланың яшәү минимумына тиң. Татарстанда ул быел 1 гыйнвардан 11 мең 852 сум тәшкил итә. 2023 елга кадәр ана капиталыннан түләүне гаиләдәге икенче балага гына түләсәләр, быелдан ул өч яшькә кадәрге һәр балага да бирелә.

Тагын бер бердәм түләү көне – һәр айның өчесе. Бу көнне 17 яшькә кадәрге балаларга һәм йөкле хатын-кызларга бердәм пособие килә башлаячак. Хәер, илнең кайбер төбәкләрендә яңа тәртипкә күчкәннәр дә инде. Айның һәр өченче числосында узган ай өчен исәп-хисап ясала. Саннардан күренгәнчә, илдә 4,2 миллион балага әлеге төр түләү билгеләнгән. Яңа пособие моңарчы гамәлдә булган ярдәм чараларын берләштерде һәм быел 1 гыйнвардан гамәлгә керде. Ул айлык кереме җан башына бер яшәү минимумыннан түбән булган гаиләләргә түләнә. Шул ук вакытта, гаиләнең милке дә исәпкә алына. 1 гыйнвардан Татарстанда яшәү минимумы җан башына 12 мең 219 сум тәшкил итә.

– Пособиеләр үзеннән-үзе бердәм түләү көннәрендә килә башлаячак. Моның өчен беркая да мөрәҗәгать итәргә кирәкми. Әти-әниләр бу хакта алдан ук белеп торсын өчен, аларга «сәлам хатлары» җибәреләчәк, – диде Социаль фондның Татарстандагы идарәчесе Эдуард Вафин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Наил МӘҺДИЕВ, Чаллы мэры:

Кирәкмәгән эш белән мавыкмасын дип, мине җиденче сыйныфтан соң ай ярымга эшкә урнаштырдылар. Өчәр ай ял иткәнне хәтерләмим. Аңа карап кына берни дә булмады. Безне кызганып, яныбызда бала хокукларын яклаучылар да, прокурорлар да йөгереп йөрмәде. Барысы да әйбәт иде. Физик яктан нык булдык, хезмәт хакы алдык, эшчеләр белән бер ашханәдә ашадык.

(Аппарат киңәшмәсендә сөйләгәннәрдән)

ТАТАРСТАНДА – СӨТ ҖИТЕШТЕРҮ

Узган тәүлектә республикада 4 мең 549,8 тонна сөт савып алынган. Бу узган елгыдан 12 процентка күбрәк.

ИҢ КҮП СӨТ САВУЧЫ РАЙОННАР

Район		1 көндә савылган сөт, т	1 сыердан савылган сөт, кг	Сыер саны
1	Кукмара	420,0	26,6	15779
2	Балтач	345,6	25,3	13634
3	Әтнә	328,9	29,9	10989
4	Саба	307,5	28,3	10860
5	Актаныш	229,0	22,8	10056
6	Мамадыш	223,0	26,9	8300
7	Арча	198,0	21,4	9255
8	Азнакай	192,0	19,0	10084
9	Әлки	165,8	15,1	10973
10	Минзәлә	152,4	27,6	5516



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

НЕФТЬ КУЕЛЫГЫНДА ЮРАУ

Глобаль капитализмның рәсми пропагандасы, рецессия юк, финанс кризисы юк, дип күпме генә ышандырырга тырышмасын, икътисад түнтәрелеше планетаның бар почмаклары буйлап тарала. Чынлыкта, рецессия – җитештерүнең кимүе Көнбатышта үткән елда ук башланды, аны яшерергә генә тырыштылар. Эшләрнең уңга бармавын күрсәтүче төп индикатор – чималга, бигрәк тә нефтькә бәяләр. Моннан өч ел элек язгы якта «кара алтын» бәяләренең ничек җимерелеп төшүен искә төшерик әле. Ул чакта Согуд Гарәбстаны, базардан Россия нефтен алып ташларга теләп, «кара алтын» җиһады» башлады: базарларны арзанлы чимал белән тутырган иде. Әмма гарәпләр бик тиз айнылылар: үзара килешеп, җир маен чыгаруны киметүдән дә уңай ысул юк икәнлеген төшенделәр. Дөрес, ул чакта Мәскәү үзе Әр-Рияднның ачуын чыгарды: углеводород державасы тәкъдим иткән шартлар белән башта ризалашмаган иде. Эшнең начар икәнен аңлап, ике як та нефть чыгаруны кискен һәм масштаблы киметтеләр. Шуннан соң арту бик аз гына булды, пандемия алдындагы күләмгә беркайчан да ирешелмәде. Шуңа карамастан «кара алтын» бәясе бик әллә ни күтәрелмәде. Икътисадый активлыкның түбән булуы – моңа төп сәбәп, һәм углеводород чималы чыгаручы илләр, пандемия чикләүләре бетү белән, җитештерү югарыга ыргылыр, бәя дә күтәрелер, чимал сату да артыр дип өметләнделәр. Өметләр бигрәк тә Кытай белән бәйләнде, чөнки чималны иң күп сатып алучы держава шул. Пекин халык басымы астында чикләүләрне алды, пандемия дәһшәте дә үтте. Юаньның сәүдә валютасы буларак дөнья базарларын яулавы да Кытай икътисадын югары күтәрер төсле иде. Вәләкин әҗәткә баткан Азия гиганты бик авыр сулыш ала, көтелгән тизләнү һәм ыргылыш күренми. Кытай Халык Республикасының Дәүләт статистика идарәсе гыйнвар – февральдә эре сәнәгать предприятиеләренең табышы, еллыкка күчереп исәпләгәч, 22,9 процентка кимеде, дип хәбәр итә.

Хәлләрнең мөшкел булуы алар әйтмәсә дә аңлашыла, чөнки ОПЕК+ илләренең лидерлары шимбә – якшәмбе көннәрендә, картельне җыеп та тормыйча, «кара алтын» чыгаруны үз ирекләре белән масштаблы киметү турында белдерү ясадылар. Согудләр 500 мең баррельне алып ташлыйлар, Гыйрак – 211 мең, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре – 144 мең, Кувейт 128 мең баррельдән баш тарта. Башка илләр азрак күләмдә киметә. Россия нефть чыгаруны 500 мең баррельгә киметү турында игълан иткән иде инде. Саннарны кушкач, сумма шактый зур чыга. Бездә төн булганда, Көнчыгыш биржаларында нефть бәясе 7 процентка күтәрелде. ОПЕК+ илләре 10 процент күтәрелешкә өмет итәләр. Карарның утырышка җыелмыйча да бик ашыгыч кабул ителүе дөнья икътисадында зур бәхетсезлек туып килүен искәртә. Кризисларны фаразлау белән дан казанган икътисадчы Нуриэль Рубини, АКШта күпчелек банклар техник яктан түләүгә сәләтсезлек чигенә якынайды, йөзләгән банк инде түли алмый, дип белдерде. Дөрес, бу – 1 апрельдә таратылган белдерү, әмма…

Россиядә

КАРА КӨНГӘ ДИГӘН АКЧА КИМИ

Дөньякүләм түнтәрелешнең билгеләре Россиядә дә күренми калмый, билгеле. Үзәк банкның үткән елгы финанс уңышлары сөендерерлек түгел. Аларны уңыш дип әйтеп тә булмый. Регулятор үзенең еллык хисабында дүрт банкның аздан гына түнми калуын әйтә. Үзәк банк кредиты белән генә җан асрап калганнар. Илнең төп финанс оешмасы үзе дә масштаблы югалтулар кичерә. Үткән ел 721 миллиард сумлык зыянга эшләгән. Зыян күләме 2021 ел белән чагыштырганда 27 тапкыр (!!!) арткан. Санкцияләрнең зыяны юк дигән фикерне артка алып ташлый торган саннар бу. Һәрвакыт оптимист булып калырга яратучы Путин да санкцияләрнең Россия икътисадына зыяны көтелүен таныды. Шул ук отчетта россиялеләрнең ипотека буенча бурычлары 14 триллион сумнан артып китте дигән сан да күренә. 2022 елда ике һәм аннан күбрәк кредит алган бурычлылар саны 50 процентка арткан. Биш кредит тупларга башы җитүчеләр аеруча күбәя икән.

Хәлләрнең торышы финанс өлкәсендә генә түгел, җитештерү тармагында да начарая. Февральдә җиңел автомобиль җитештерү, үткән елның шул чоры белән чагыштырганда, 70 процентка кимгән. Йөк автомобильләре һәм автобуслар җитештерү саннары да кискен түбәнәя. Май аенда АвтоВАЗ яңадан туктаячагын игълан итте: комплектлаучы импорт детальләр юк. Автомобиль алырга халыкның акчасы да юк.

Кредитлар үсә, ә менә банк депозитында саклык акчасы март кары кебек эри икән. Халыктан сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәтә: 2022 елда россиялеләрнең 80 проценты саклык акчасын тулысынча яисә өлешчә югалткан.

Быелның гыйнварында сораштыруда катнашкан гаиләләрнең 51 проценты саклык акчалары булуын таныган. Март ахырына андыйлар саны 49 процентка калган. Кара көнгә дигән акчаның күләме дә бик әллә ни түгел икән. Гаиләләрнең 40 проценты маяның өч айга да җитмәвен әйткән. 30 процентының өч айдан алты айга кадәр саклык акчасына җан асрарлык мөмкинлеге бар икән. Гаиләләрнең 10 проценты бер елдан өч елга кадәр җитәрлек запасы булуын яшермәгән. Бу – «Ромир» холдингы үткәргән сорашу нәтиҗәләре. Үзәк банк үз отчетында быелның ике аенда халыкның реаль керемнәре турында мәгълүмат бирмәгән. Бер ел элекке саннарны күрсәтү белән генә чикләнгән. Рәсми чыганакларның мәгълүматы да төгәл түгел. Иң бай кешеләрнең кереме турындагы Росстат саннары белән Үзәк банк саннары 20 процентка аерыла, мәсәлән.

Үзәк банк презентациясендә бер кызыклы факт бар. Бары тик гаиләләрнең 20 процентының гына җан башына айлык кереме 30 мең сумнан артык. Менә шул 20 процент, теләсә, кара көнгә бераз акча туплый ала да инде. Чыгымнарның артуы шартларында керемең 30 меңгә дә җитмәсә, артыгын кылана алмыйсың. Шулай да бездә хәлләр түзәрлек әле. Ливанда үткән ел инфляция 190 процент булган, Сүриядә – 139, Суданда – 63, Төркиядә – 55, Иранда – 53.

БЕЗНЕКЕЛӘР ЧЫДАМ, ӘММА УСАЛ

Ният

Татарстанда татар бал кортларын яңартмакчылар, саннарын ишәйтмәкчеләр. Бу максатлардан быел республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы әлеге төр кортларны үрчетергә теләүчеләргә субсидияләр бирүе турында да игълан итте. Бу эш ни өчен кирәк һәм авырлык нидә? Без шуны белештек.

Безнең илдәге хуҗалыкларда Урта рус токымлы бал кортларын үрчетәләр, Татар бал корты – шуларның бер төре.

– Аларның кайсыдыр төре зуррак, кайсыдыр тизлеге, башка үзенчәлекләре белән аерылып тора, – ди министрлыкның терлекчелекне үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе Алмаз Гамиров. – Безнеке – чиста татар популяциясе – суыкларга чыдам, шунлыктан алар кышны яхшы чыга. Икенчедән, алар балны күбрәк җыя, табышлары көненә 8–12 килога кадәр җитәргә мөмкин. Бу төр кортлар бер җирдән икенче җиргә күчеп йөрми, балны бер урыннан гына туплый. Чөнки озак еллар дәвамында кортларның аңында «Җәйге сезон кыска, уңышны тиз арада җыеп бетерергә кирәк» дигән «уй» формалашкан. Шуңа күрә алар атна-ун көн эчендә балны җыеп бетерергә яраклашкан. Безнекеләрдән аермалы буларак, көньяк төрләр балны озаграк, иркенләбрәк туплый. Өченчедән, безнең кортлар авыруларга чыдам. Шул ук вакытта алар, башка кортлар белән чагыштырганда, усалрак, шуңа күрә аларны белеп тәрбияләргә кирәк.

Менә шундый өстенлекләргә ия булсалар да, кызганыч, соңгы 10–15 ел эчендә республикада аларның саны шактый кимегән.

– Интернет барлыкка килү белән, умартачылар төрле токымнар белән кызыксына, аларны төрле җирләрдән алып кайта башладылар. 2010 еллардан башлап хәзергә кадәр Карника, Бакфаст дигән токымнар керә. Татар бал корты – республиканың горурлыгы, һәм аны саклау – безнең бурычыбыз. Ул – буыннан-буынга тапшырылган мирас. Әгәр аны югалтабыз икән, киләчәк буын безне аңлармы? – ди Алмаз Гамиров.

Моннан тыш, белгеч фикеренчә, әлеге төрне үрчетү авыруларны булдырмый калырга ярдәм итәр иде.

– Көньяк бал кортлары белән төрле авырулар да керергә мөмкин. Шул ук вакытта алар кыйммәтрәк тә – бер гаиләсе (монда өч рам, ана корт (матка) һәм бер килограмм бал корты) 3 мең сум тора. Болар әле – сертификатлары булмаган, селекциясез кортлар. Ә безнекеләр, чиста токымлылар, 2,5 мең сум торачак, – ди ул.

Ләкин Татар бал кортларын саф токымлы итеп саклап калу җиңел эш түгел. Чөнки алар төрле төрләр белән кушылып, саф токым булудан туктый. Моның өчен ясалма ысулларны һәм яңа технологияләрне эшкә җигәргә туры киләчәк. Белгечләр нәрсә тәкъдим итә соң? Беренчедән, татар популяциясен лаборатория шартларында үрчетү күздә тотыла. Ләкин шулай ук тискәре үзлекләре булуын искә алып, массакүләм кулланып булмаячагын әйтәләр. Икенчедән, бал кортларын башка төрләр керми торган «утраучык»ларга чыгарып аталандырмакчылар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Татар бал кортларын яңарту җиңел һәм тиз башкарыла торган эш түгел. Субсидия алыр өчен, башта токымга статус алырга кирәк. Әлегә без башлангыч этапта торабыз. Субсидияне республиканың барлык умартачыларына ярдәм буларак карарга кирәк. 2,5 мең сумга үзебезнең саф токымны алырга була. Сатучыга чыгымнарының 50 проценты кайтарыла, – дип аңлатты министрлык вәкиле.

Хәзерге вакытта Татарстанда чиста Татар бал кортлары белән барлыгы өч хуҗалык шөгыльләнә. Алар Саба һәм Балтач районнарында урнашкан. Өч хуҗалык 600 бал корты пакеты җитештерергә сәләтле, ә Татарстанда моңа ихтыяҗ елына 2–3 меңне тәшкил итә. Теләче районыннан Нияз Сабирҗанов та әлеге төр кортлар белән озак еллар шөгыльләнә, бу көннәрдә ул сертификат алу мәшәкатьләре артыннан йөри.

– Әти гомер буе Урта рус токымлы кортлар тотты. Мин дә аның эшен дәвам иттерәм. Хәзерге вакытта 300 баш татар бал кортыбыз бар. Тик моңа кадәр сертификат алыр өчен шартлар туры килми иде, быелдан аны бераз йомшарттылар. Узган елларда сертификатны бары тик шәхси эшмәкәрләр генә алган булса, быелдан фермерларга да мондый мөмкинлек бирелде, – диде ул.

Умартачы әйтүенчә, үзебезнең кортлар балны яхшы җыя һәм ул тәме, шифалы булуы белән дә аерыла. Галимнәр аның сыйфаты да яхшырак булуын дәлилләгән.

– Соңгы елларда Татарстанда җылы як бал кортлары күп таралды, тик алар кышны авыр чыга. Безнекеләр исә бу яктан бик уңайлы, – ди Нияз Сабирҗанов. – Корт гаиләләрен электән үк сата идек, тик кулыбызда документ кына булмады. Хәзер безгә кортларны тикшертеп, аларның нәкъ менә шул төр икәнлекләрен расларга кирәк булачак.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Солдат шулпасы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, «Госуслуги.ру»да моңарчы гамәлдә булган шәхси битне бетерү төймәсе дә юкка чыкты. Дөрес, соңрак илнең Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгында моның хәрби чакырылышка бернинди дә катнашы булмавын, бары тик «шәхси бит»ләрне шул рәвешле мошенниклардан сакларга тырышуларын аңлаттылар. Ничек кенә булмасын, хәзер Дәүләт хезмәтләре порталыннан «чыгып китү» өчен иң элек гариза юлларга кирәк.

Күп тә үтмәде, электрон чакыру кәгазьләре турындагы хәбәрне кире кагада башладылар. «Законда мондый ысул каралмаган», – дип белдерде Дәүләт Думасының Оборона буенча комитеты җитәкчесе Андрей Картаполов. Бер үк комитетта капма-каршы ике фикер кайдан килеп чыкканы сер булып калды. «Чакыру кәгазе фәкать кулдан-кулга гына тапшырыла ала», – дип өстәде Федерация Советының Оборона һәм иминлек буенча комитет җитәкчесе Виктор Бондарев. Әлегә кадәр илнең Оборона министрлыгыннан бу хакта төгәен мәгълүмат юк.

– Чакыру кәгазьләрен электрон рәвештә тарата башлау өчен, иң элек гамәлдәге канунга үзгәрешләр кертергә кирәк, – ди хәрби хезмәткә чакырылыш мәсьәләләре буенча юрист Илнур Мортазин. – Хәзер исә бары тик кулдан-кулга тапшырылган «повестка»лар гына хокукый көчкә ия. Ягъни документны кабул итеп алучы моны раслап кул куярга тиеш. Ә интернетта моны ничек дәлиллисең? Әти-әниләр: «Электрон чакыру кәгазе килеп төшсә, нишләргә?» – дип борчылып шалтырата башлады инде. Бу очракта хәрби комиссариатка барыргамы-юкмы, бу – һәркемнең үз эше. Әлегә моның өчен бернинди җаваплылык та каралмаган. Шул ук кесә телефонындагы кушымтаны теләсә кем ачып карарга мөмкин бит.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Килеп җиттеме яз?

Урамда кояшлы булгач, рәхәт. Әмма язның болай иртә килүе барыбер шикләндерә. Кинәт кенә суытып җибәреп, кәефне бозмасмы соң? Бу хакта белгечләрдән сораштык.

Сарманда яшәүче халык синоптигы Илдар Әшрәфуллин инде 35 ел дәвамында һава торышын күзәтеп, теркәп бара. Аның әйтүенчә, соңгы вакытта язның болай иртә килгәне булмаган. Шуңа күрә һичшиксез суытачак, дип фаразлый ул. Май башында кары да, яңгыры да төшәчәк, ди.

– Яз тиз генә килә алмый. Җир кипкәннән соң әле безнең Каравыл тавын кар каплый иде. Быел капламады. Кыш салкын булмады. Тик табигать еллык температураны барыбер тигезли, – ди халык синоптигы. – Март, апрель җылы, ә май салкын булса, иген уңа дип әйтәләр. Май ахыры, июнь башларында да яңгырлар булырга тиеш.

Казан федераль университетының метеорология кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев белән дә сөйләштек.

– Быел яз ике атнага иртәрәк килде. Температура, күпьеллык климатик күрсәткечләр белән чагыштырганда, 1–2 градуска гына артыграк булырга тиеш, ә бүген инде уртача тәүлеклек температура 10 градуска җитте. Җылы һава торышы берничә көн сакланачак. Көндез температура 15 градустан да түбән булмас. Шуннан соң Скандинавия антициклоны килү сәбәпле, температура бераз түбәнәячәк, ягъни пәнҗешәмбегә 6 градус булачак. Ни өчен дигәндә, төньяктан һава агымы килә. Әле чын яңгырлар көтелми, – ди Юрий Переведенцев.

Аның әйтүенчә, апрельдә, гадәттә, явым-төшемнәр бик аз була. Хәзерге вакытта ул – 32 миллиметр. Чагыштыру өчен: июньдә – 70 мл. Россия гидрометеорология үзәге фаразлавынча, температура хәзер климатик нормадан бер генә градуска артыграк булырга тиеш. Апрель – җылы ай. Салкыннар әле кайтырга мөмкин.

«Ни өчен яз иртә килде?» дигән сорауга да җавап бирде ул.

– Безгә әле Атлантикадан һаман җылы циклон килә. Шуңа күрә кар да тиз бетте, яз да иртә килде. Арктикадан йогынты булуга, температура түбәнәергә, кар да яварга мөмкин. Тик кайчан икәнлеген әйтеп булмый. Хәзер Санкт-Петербургта салкыннар күзәтелә, кар да төшкәли. Безгә кадәр килеп җитми, чөнки океаннан ераграк урнашканбыз. Һәр яз саен суытмыйча калмый. Тик ул кыска вакытлы гына булачак. Кайчак июньдә дә кар ява, тик андый очраклар бик сирәк, – ди Юрий Переведенцев. – Март бик җылы һәм яңгырлы булды. Аннан май салкынчарак килсә, уңышка файдасы булыр, дигән сынамыш та бар.

Сәрия МИФТАХОВА

ЭНӘСЕЗ БУЛМЫЙ

Кисәтү

Татарстанда коронавирус, грипп белән бәйле вазгыять тотрыклы булып кала бирә. Аның каравы соңгы арада бездә кызамык йоктыру очраклары арта башлаган. Барысы да республикага читтән килеп эшләүчеләрдә ачыкланган. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина хәбәр итте.

Саннар теләнә күчсәк, ел башында республикада кызамык йоктыруның 6 очрагы теркәлгән булса, февраль – март аенда бу сан 13кә җиткән. Шуларның 11е республикага Таҗикстаннан килгән, калган икесе Новосибирск һәм Төмән кешесендә ачыкланган.

– Билгеле булганча, әлеге авыру һава аша йога. Ул хәтта вентиляция юлы буенча да бик тиз таралырга мөмкин. Күпфатирлы торак йортта бер кеше кызамык йоктырган булса, ул йортта яшәгән бар кешегә дә куркыныч яный дигән сүз. Аннан саклану өчен вакцина ясатырга кирәк. Башка очракларда ул календарь буенча ясалса, авыру белән аралашкан кешегә, яшенә карап тормастан, тиз арада ясалырга тиеш, – ди Любовь Авдонина.

Сан

Россиянең башка төбәкләрендә дә хәлләр мактанырлык түгел. Моңа кадәр илдә кызамык йоктыруның берәр генә очрагы теркәлгән булса, бүген инде һәр төбәктә диярлек әлеге инфекцияне йоктыручылар саны арта. Ленинград (ел башыннан бирле 77 кеше йоктырган), Кузбасс (33 очрак), Томск (21 очрак), Мәскәү өлкәләрендә (30 очрак), Дагыстанда (100дән артык) хәлләр аеруча мөшкел дип бәяләнә.

Вазгыятьнең катлаулана баруын истә тотып, Роспотребнадзор идарәсе 3 апрельдән ил күләмендә кызамыкка каршы «чистартучы» вакцинация башлап җибәрде. Әлеге махсус чара барышында кызамык белән бер тапкыр да авырмаган, әлеге чиргә каршы прививка ясатмаган кешеләргә вакцина ясау күздә тотыла. «ВТ» элемтәгә кергән белгечләр дә кызамыкны кисәтергә ярдәм итүче иң төп чара дип прививка ясатуны атый.

Казанның 21 номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-терапевты Регина Галиуллина белдерүенчә, мондый алым нәтиҗәлелеген күптән раслаган.

– Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, кызамыкка каршы массакүләм вакцина кертелгәч, дөнья күләмендә әлеге инфекцияне йоктыру очраклары 75 процентка кимегән. Башка прививкалар кебек, аннан соң да өзлегүләр булырга мөмкин, әлбәттә. Кызамыкка каршы вакцина ясаткан урын авыртырга, кызарып, шешеп торырга мөмкин. Прививка ясатканның 5–12 көннәрендә тәнгә тимгелләр чыгарга, температура күтәрелергә, аякны көзән җыерырга мөмкин. Әмма моннан куркырга кирәкми. Болар бар да – прививка ясатканнан соң күзәтелергә мөмкин булган гадәти, вакытлы күренешләр, – ди табиб.

pixabay.com

Кызамык өлкәннәр арасында сирәк очрый. Ул, нигездә, балалар арасында киң таралучы вируслы авыру санала. Күбрәк 2–5 яшьлек балалар арасында ачыклана. 11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы Гөлназ Азизова аны иң мәкерле чирләрнең берсе дип атый. Ник дигәндә, баштарак ул гадәти ОРВИ вакытындагы кебек билгеләр белән башлана. Өстәвенә бик тиз тарала да. Кызамык йоктырган кеше белән аралашкан кеше 90 процент очракта бу чир белән үзе дә авырый.

– Кызамык еш кына гадәти ОРВИ кебек башлана. Шуңа күрә баштарак табиб аны төгәл ачыклап бетермәскә дә мөмкин. Беренче көннәрдә бала ютәлли, тамагы авырта, борынга томау төшә. Аны бизгәк тотарга, күзенә конъюнктивит чыгарга да мөмкин. Әмма кызамык башлануның дүртенче көнендә тәнгә кызыл тимгелләр чыга башлый. Ул тиз арада тарала, артканнан-арта бара. Баштан алып аяк бармакларына кадәр кызыл тимгелләр чыга. Бала коңгырт кызыл төскә керә. Тәнгә тимгел чыкканда, баланың температурасы 40 градуска кадәр күтәрелә. Ул яктылыктан курка башлый. Дүрт көн дәвамында баланың температурасы бик югары була. Аннары тимгелләр акрынлап кими, – ди табиб.

Тимгелләр бетеп, баланың хәле тиз арада уңайланса, ярый да. Әмма авырып терелгән балада еш кына бик җитди өзлегүләр дә күзәтелә, ди табиб. Андый чакта менингит башланырга, аякларны көзән җыерырга мөмкин.

– Кызамык бөерләргә дә бәрә. Анысы бигрәк тә куркыныч. Ник дигәндә, ул үлем-китемгә үк китерергә мөмкин. Балада кызамык билгеләре күзәтелүгә, кичекмәстән табиб чакыртырга кирәк. Чирне кисәтү өчен исә прививка ясатудан да нәтиҗәлерәк чара юк. Элегрәк, кызамыкка каршы прививка кертелгәнче, әлеге чирдән үлем-китем очраклары 15 процентны тәшкил иткән булса, хәзер ул – 2,1 процент чамасы. Бу – нигездә, прививка ясатмаган балалар. Кызамыкка каршы вакцина ясаткан бала, чирне йоктырган очракта да, аны җиңелрәк уздыра, – ди табиб.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

УКУЧЫ СҮЗЕ

Җитәкчедән уңдык

Алексеевск районының Түбән Тигәнәле авылы район үзәгеннән 30 чакрым ераклыкта, табигатьнең матур җирендә, ямьле инеш буенда урнашкан. Урта Тигәнәле җирле үзидарәсе составына керә. Авылыбыз зур түгел, бирелә нигездә өлкән яшьтәге кешеләр яши. Фельдшер-акушерлык пункты, спорт комплексы, мәдәният йорты, китапханә, мәчет, кибет эшли.

Пенсионерларның көндәлек тормышында төрле мәшәкатьләр туып кына тора: кайсының краны ватыла, кеменең өй түбәсеннән су ага, кайберләренең коймасы ава. Мондый очракларда алар җирле үзидарә башлыгы Илдар Хәмәтвәлиевкә мөрәҗәгать итәләр һәм һәрчак ярдәм, ялкау табалар.

Җитәкчебезнең тырыш хезмәте күзгә күренеп тора: ул, кыш көне үзе тракторга утырып, иртән иртүк авыл эчендәге юлларны чистарта, сууткәргеч белән килеп туган проблемаларны вакытында хәл итә, өлкән яшьтәге кешеләрнең борчу-мәшәкатьләрен һәрчак белешеп тора. Хәленнән килгәнчә ярдәм итә, үзе башлап йөри. Халык та аның тәкъдименә беркайчан да каршы килми, бергә зиратларны җыештыралар, өй яны территорияләрен тәртиптә тоталар, өмәләрдә һәм экологик акцияләрдә актив катнашалар.

Илдар Кәлимуллович үзенең игътибары һәм хезмәт сөючәнлеге белән авыл халкы арасында абруй һәм хөрмәт казанды. Шундый тырыш, миһербанлы, ихтирамлы, шәфкатьле, мәрхәмәтле ул үстергәннәре өчен авыл халкы аның әти-әнисенә дә бик рәхмәтле. Җитәкчебезгә эшендә зур уңышларга ирешүен, саулык-сәламәтлек, бәхет-шатлыклар, гаилә иминлеге телибез.

Авыл халкы исеменнән, Роза СӘЛАХИЕВА

Наҗар НӘҖМИ

Елаган ат турында

Атны, елый, диләр... Мәнә элек
Атлар гына йөргән урында
Хәзер инде сыер тапап үткән,
Чучка сөреп беткән болында

Башын иеп, бер күк бия тора,
Ялын тараган да җил инде.
Ә ул, мәхлук, үз язмышын уйлап,
Эчтән генә елый шикелле.

Елый кебек җилгә очкан өчен
Ир канаты белән зур даны.
Тарткан өчен бөтен тормыш йөген,
Сөйрәгәне өчен дөньяны.

Елый кебек колынына карап,
Килачәген тоеп колынның.
Ә ул, гамьсез, кешнәп, уйнап йөри,
Чабып йөри бетерен болынны!

Әйтерсең лә аның өчен генә
Туган җире, туган кырлары.
Колын белән бергә чабып йөри
Хыялларым минем, җырларым.

Ничек башың күккә тимәсен!

Якташыбыз Илсөяр Хәйруллинаның быел 7 февраль санында «Балга ябышкан бөҗәк кебек» дигән язма-истәлеген укыгач, һәрчак өстәлем түрендә булган «ВТ»га һәм эшчән, бердәм коллективына рәхмәт-хөрмәтемне җиткерергә уйладым.

Өстәвенә Илсөяр ханым – якташыбыз, үзебезнең Үчәлле авылы кызы. Республика күләмендә ике горурлыгыбыз бар иде без үскән чакларда. Беренчесе Илсөяр Хәйруллина булса, икенчесе – Рәшит Зәкиев, Тымытык авылы тумасы, «Социалистик Татарстан»ның районнардагы үз хәбәрчесе һәм озак еллар «Чаян» журналының бик абруйлы баш мөхәррире. Икесе дә – Россиянең атказанган журналисты! Хәбәр, инша-язмаларның башта район газетасында, «Яшь ленинчы», тагын да ары «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан»да басылып чыкканын түземсезлек белән көтеп, башым күккә тигән чакларда, гел менә шушы ике фамилияне күзәтә идем. Алар кебек буласым килде. «Социалистик Татарстан» бик яшьли үзенә тартып, хәбәрче-журналист итеп үстердә төп рольне уйнады дисәм, дөреслеккә туры килер. Гәрчә үземне тулаем районыбыз газетасына багышласам да, «ВТ» минем өчен, чын-чынлап, иң яраткан, иң хөрмәтле-абруйлы басма булды һәм булачак!

Илсөяр Хәйруллина әйткәнчә, мин дә архивымны актарып утырам. «Социалистик Татарстан»ның 60 еллыгы уңаеннан, 1982 елның 5 маенда Матбугат көне уңаеннан баш мөхәррир Шәмси Хамматов миңа, бер авыл егетенә, олылап, Мактау грамотасы җибәргән – ничек башың күккә тимәсен! Менә монысы да – «Социалистик Татарстан»ның 1987 елгы 6 февраль санында чыккан бик кадерле хәбәр-истәлек. Анда болай диелгән: «Татарстан Журналистлар идарәсе бюросы карары белән 1986 елгы эш йомгаклары буенча республика журналистлар оешмасының Мактау китабына кертелделәр: «Социалистик Татарстан» газетасының бүлек мөдире Мөнир Абдулхакович Абдуллин, Азнакай районында чыга торган «Маяк» газетасының бүлек мөдире Әсгать Хаҗиевич Сәгыйтдинов». Шул вакытлардан бирле «ВТ»да күпме язмаларым дөнья күрде. Бүген дә йөзъяшәр тарихлы иң яраткан газетамнан аерылмыйм, хәбәрләшеп-язышып торам. Һәр санын түземсезлек белән көтеп алам. Матбугат ветераны өчен бу бик тә горурланырлык дәрәҗә инде!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай

КЫШ УРТАСЫНДА – ҖИР ҖИЛӘГЕ

Документаль проза остасы, әзтабар язучы Шаһинур Мостафин белән мин якынннан 2010 елда Казан Кремлендәге «Бөек Ватан сугышы» музей-мемориалында танышкан идем.

Бөек Җиңүнең 65 еллыгы уңаеннан «Мәгариф» журналы «Бөек Җиңү кайтавазы» дигән бәйге игълан итте. Мин дә җиңүчеләр рәтендә булып, «Җиңү даны мәңге сүрелмәс!» дип аталган фәнни-гамәли конференциягә чыгыш ясарга чакырылган идем. «Абыем, сине эзлим...» дип аталган публицистик мәкаләм белән залдагыларны таныштыргач, Шаһинур абыйга мөрәҗәгать итеп: «Әниемнең абыйсы – Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган Сәетнәсим Бадретдиновның язмышы турында беләсем килә», – дидем һәм кулымдагы язмамны аңа тапшырдым.

Сәбәбе дә бар. Эзтабар язучы буларак, Шаһинур Әхмәтсафа улы – Татарстан Язучылар берлеге каршындагы «Хәтер яктысы» берләшмәсенә җитәкчелек иткән һәм Германиягә, Балтыйк буе дәүләтләренә, Украинаның күп кенә төбәкләренә, шулай ук Россиянең күнбатыш өлкәләренә экспедицияләр оештырган шәхес. Өстәвенә ул архивларда казына, сугыш ветераннарыннан истәлекләр язып ала. Шулар нигезендә очерклар, мәкаләләр, документаль фильм сценарийлары һәм, әлбәттә, әдәби әсәрләр иҗат итә. 2007 елда ул, эзтабарлык өлкәсендәге һәм иҗаттагы казанышлары өчен, Россия Федерациясенең Михаил Ломоносов исемендәге премиясенә һәм алтын медальгә лаек була.

Шаһинур абый белән икенче очрашуыбыз ул 2006 елдан бирле баш мөхәррир йөрген тарткан «Сүз» нәшрияты редакциясендә булды. Мин аның янына әле генә «табадан төшкән» «Җырлы чишмә» исемле китабымны бүләк итәргә дип кердем. Кырык данәсен Мамадыш районы Тулбай авылына – Шәйхи Маннурның музей-китапханәсенә кайтарып тапшыруын үтендем. Иҗат юлымда Шәйхи аганың алтынга тиң киңәшләре бик ярдәм итүен дә әйттем.

Бервакыт шулай тулбайлылар мине кышкы шигырь бәйрәменә чакырдылар. Иртән иртүк Татарстан Язучылар берлеге машинасында юлга кузгалдык. Шәйхи аганың туган ягына аяк басуга, минем өчен дулкынландыргыч минутлар башланды.

Башта шаһәр үзәгендәге һәйкәле янында шигъри митинг тантанасы булды. Өченче татар мәктәбендә татар теле укытучылары, китапханәчеләр, укучылар алдында шигырьләребезне укыдык, сорауларга җавап бирдек. Якташлары Миңгол Галиев башкаруында Шәйхи Маннур шигырьләренә язылган җырларны тыңлап сөендек. Менә Шәйхи аганың туган авылы Тулбай! Кунакчыл халык безне нәкъ кыш уртасында җир җиләгеннән авыз иттерде. Әдипнең каберен зиярәт кылдык. Шәйхи Маннур исемендәге музей-китапханәдә экспонатлар белән таныштык.

Шаһинур абый миңа карата изге хәер-фатиха булуын Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең кабул итү комиссиясенә тәкъдимнамә язып та раслады. «Ниһаять, татар әдәбияты мәйданында беркемне дә кабатламый торган үзенчәлекле яңа шагыйрә, прозаик һәм публицист пәйда булды. Өстәвенә әле ул заманында атаклы фронтовик-шагыйрь Шәйхи ага Маннур белән якыннан аралашкан, Казанда югары уку йортында белем эстәгәндә, олуг әдибебезнең фатирында яшәп, аннан әдәби дәресләр дә алган асыл зат икән. Шуңа күрә аның «Җырлы чишмә» дип исемләнгән беренче китабын, төнен дә йокламыйча, бер тында укып чыктым һәм ныклы фикергә килдем: әдибә бар!» – дигән ул.

Киң күңелле изге җан иде шул Шаһинур абый. Аның миңа булган ышанычын тулысынча аклыйсы иде дигән хыял белән яшим хәзер.

Рухия АХУНҖАНОВА.
Чаллы

АШЛЫК КИПТЕРГӘНДӘ КИМИ

Авылдашым, Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиеваның концертын тыңлаганда, аның әти-әнисе һәм туганнары турында уйланып утырдым.

Зөһрәнең моңлы сандугач булып китүенә сәбәпләр шактый. Сарман районы Салих-Тукай авылының гаҗәеп гүзәл табигате аның талантын ачарга һәм үстерергә мөһим эзәргеч булгандыр. Булачак җырчыбызның йортлары да урман эчендәрәк, сандугачлар сайравын тыңларлык урында урнашкан иде. Йортларыннан 20–30 адым ераклыкта гына челтерәп аккан чишмә да аңа «Җидегән чишмә»не сандугачлар көнләшерлек итеп башкарырга булышкандыр.

Әтиләре Котдус абыйның гармунда уйнавына әниләре Миңнегөл апа һәм дүрт апасының кушылып җырлавын ишетеп үскән Зөһрә моңсыз бала була алмый, билгеле. Аның әнисе белән минем Хәнифә әнием ахирәтләр иде. Очрашкан саен моңлы итеп мөнәҗәтләр, кыйссалар көйләп укыдылар. Зөһрәнең әтисе Котдус абый колхозның ашлык амбарында мөдир булып эшләде. Ул авыр елларда әниләргә, басуда урак урып, көлтә бәйләп, нормаларын үтәсәләр, 200 грамм умачлык он бирделәр. Котдус абый бик гадел рәвештә, граммын граммга үлчәп, гөнаһ кертмичә, һәр колхозчыга өләшә иде.

1947 елның көзе бик яңгырлы килде. Хөкүмәткә ашлыкны чистартып, киптереп җибәрү бик мәшәкатьле булды. Колхозның чи ашлыкны киптерү өчен утын ягып кыздыра торган бик кечкенә сушилкасы тәүлегенә 4–5 центнердан ары киптерә алмады. Кемнең мунчасы бар, шуларга үлчәп өләшәләр, соңыннан үлчәп кабул итәләр иде. Беркөнне әниенең мунчада киптергән ашлыгын үлчәп кабул иткәндә, колхоз рәисе (билгеле сәбәпләр аркасында, исемен язмыйм) килеп керә. Ашлыкны алу һәм тапшыру исемлеген карагач, әнигә: «Ник ким китерден?» – дип бәйләнә башлый. Югыйсә ашлык киптергәндә кими бит инде. Әни белән рәис арасында тавыш чыга, рәис аны төртеп ега, әниемнең хәтта күз төпләре кара янып чыга. Ләкин, аңа да карамыйча, колхоз рәисе әниемне, «ашлык буры» дип, судка бирә. Суд 1947 елның 8 мартында Сарман районының Иске Дөреш авылында була. Шаһит итеп Котдус абыйны чакыралар. Ул елларда дөреслекне әйтү бик куркыныч булса да, барысын да ничек булган, шулай сөйләп бирә. Әние коткаралар, ә кыйнаган өчен колхоз рәисенә эш ачалар һәм төрмәгә җибәрәләр.

Безнең Салих-Тукай авылында Котдус абыйлар гаиләсе һәрвакыт гадел хезмәт белән яшәде, шуңа күрә авыл халкы аларга бик рәхмәтле булды. Котдус абыйны җылы хисләр белән искә алам, намаз укыганда да догаларымда, мәрхүмнең урыны оҗмахта булсын иде, дип телим. Бу истәлегемне дә, Зөһрәнең әтисе рухына дога булып ирешсен иде, дип тәмамлыйм.

Индус ФАЗЛЫЕВ.
Азнакай районы Тымытык авылы



Мәҗнүн

Милли китапханә бинасында урнашкан «MON» театр студиясендә 82 яшен билгеләп үткән халык шагыйре, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ белән очрашу – «Мәҗнүн» дип исемләнгән кичә узды. Оештыручылар – яшь буынның талантлы шагыйрәләре Йолдыз Миңнуллина һәм Эльмира Җәлилова.

Беренче баруым иде бу студиягә. Ишеген ачканчы ук, ниндидер бер яңалыкка атлавыңны тоясың: биек шома стена алдында басып торганда бигрәк тә. Фантастик кинолардагы шикелле, билгесезлеккә күчү ишегә алдында басып торгандай хис итәсең үзеңне. Башланырга вакыт күп иде әле. Шуңа күрә ишекнең ачылмавы гаҗәпләндермәде. Як-ягыма карана торгач, икенче ишектән чыгып килүче бер ханым күренде. «Әһә! Керeп була, димәк». Анда керергә яравын белдем дә ишекне ачтым. Рәхсәт сорап, алга атладым. Ярым караңгы кечкенә генә зал. «Керегез, кер», – дип, бик җылы каршы алдылар. Рекламада күргәнчә түгел, кресенчә, тамашачы «сәхнә»дә утырачак икән. Тамашачылар утырырга тиешле калкулыкта өстәл янында Рәдиф Гаташ үзе утыра. Аның янына барып исәнләшкәннән соң, өстәлләр янындагы урындыкларның ышанычсыз алып, барып утырдым. «Кызык икән монда, халык та күп булмаячак икән, ничергәк булыр икән?» дигән уйлар белән ишектән керүчеләрне күзәтәм. Күбрәк яшьләр килә. Әһә! Рабит ага Батулла да килде! Күптән түгел 85 яше тулган олпатыбыз да кичәгә килергә вакыт тапкан.

Әйбәт булды кичә. Рәхәтләнеп бөек шагыйребезнең ялкынланып укыган шигырьләрен, аның сүзләренә язылган җырларны тыңладык. Зәйнәб Фәрхетдинова, Илгиз Мөхетдинов, Илүсә Хуҗинаның үз тавышлары белән җырлаулары ишетеп хозурландык. Кичәнең музыкаль бизәлешен фортепианода талантлы музыкант Чулпан Яркаева башкарды. Җырчыларның аккомпаниаторы да ул булды. Барлык чыгышлар да бербөтен булып кабул ителде. Фортепиано тавышы чыгышларны тулыландырды, күңел моң дәрьясында йөзде.

Зуррак залда узса да шулай булыр иде, билгеле. Ярый, кичәләр арасында мондые да кирәктер, мөгаен. «Мәҗнүн» премиясенә дәгъва кылган шагыйребезнең күңеленә хуш килүен күрү – үзе бер шатлык!

«...Әгәр тормыш дигән җырга гашыйк икән,
йөрәк үзенең чын моңын табар...» –

дигән юллар бар Рәдиф Гаташның бер шигырендә. Чын моңын тапкан шагыйребезнең озын гомерле булуын тели шигърияткә гашыйк җаннар. Оештыручыларга рәхмәт әйтәсе генә кала.

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА.
Казан

КУРКЫНЫЧ СҮЗ

Олыгайган көндә артта калган гомерне барлап, нәтиҗәләр чыгарасың икән ул. Менә бүген балачак хатирәләре бимазалый. Заман балаларына карыйм да елмаям, әти-әниләре янәшә. Без исә сугышка кадәр әтине өйдә бик сирәк күрдек, ә инде сугыш елларында әниебезне дә сирәк күрдек.

Без йокыдан торганда, ул инде өйдә булмый иде. Иртән торабыз, өй җылы, өстәлдә җамаякка өеп салынган бәрәңге, тастымалга төрелгән чәйнек белән чәй. Кулларны юып килабез дә бәрәңгене сыпырып куябыз. Калса, өйлә вакытында ашап бетерәбез. Аннары үен уйлап чыгарырга тырышабыз. Чөнки өйдә уенчык та, рәсемле китап та, карандашлар да юк. Бөтен юаныч – тәрәзә аша урам карау. Ике тәрәзәне өч бала булешә, сулыш белән эретеп «глазок» ясый да күзәтә башлый. Аннан сирәк кенә булса да кешеләр үтә, йөк төягән атлар узгалыйлар. Шул да безгә сөенеч була. Өйгә атналар буе беркем кермәгән, барысы да эштә.

vk.com

Бер көнне кечкенә энекәш каяндыр кадак суыра торган зур келәшчә табып кергән. Шуның бер җабен өстәлгә куя да, икенчесен төшереп, өстәлне шалтырата башлый. Үзе: «Ашлык сугам, ашлык сугам», – дип такмаклый. Өстәлне дерелдәтә торгач, идәнгә чәй тәлинкәләре очып төшә. Кайсы ватыла, кайсы исән кала. Аларын кире өстәлгә куябыз. Урамга чыгып уйнар идек тә, киемнәр яшереп куелган. Шулай көн үтә. Өлкәннәр булмагач, мичне караучы юк, кичкә ул суына, өй суына башлый. Кичкә инде безне салкын юрган астына чумдыра. Әни эштән кичке 10нарда кайта, без инде анда йоклаган булабыз. Шулай көн артыннан көн үтә. Әнкәй бәгырь мал-туарны карый, безгә дип бәрәңге пешерел куя, мичне тергезә.

Ә беркөнне ул безне үзе кайткач утты һәм авылга «эвакуированный»лар кайтканын хәбәр итте. Аларны артык утыннары булган хуҗалыкларга урнаштыралар икән. Безнең өебез бәләкәй булгач, кеше кертмәгәннәр. Әни исә күршеләргә урнашкан «эвакуированный» мәскәүләрне кызганган икән. Аларның өйләре дә салкын, анда гел кычкырыш, ашарларына да юк, безгә алып кайтсак, ни диярсез, ди. Кечкенә кызлары да булгач, бик шатланып ризалаштык.

Иртәгесен бер бабай килеп, өстәлнең икенче башына тактадан карават ясап китте. Кич белән шаулап мәскәүлеләр килеп керде. Бер кызына – 10, икенчесенә 2 яшь икән. Кечкенә кыз тере курчак инде менә, шундый матур. Икесенең дә исемнәрен белмибез. Алар да безнең белән сөйләшмиләр. Олы кызлары иртән мәктәпкә китә, кечкенә кыз караватта тынын да чыгармый карап ята. Мин хәзер генә аның авыру булганын аңлыйм, ул вакытта каян беләсең аны. Безгә бу кызны карау бер шөгыль булды, үзебез ашаганда өч-дүрт бәрәңгене тәлинкәгә салып, аңа да китереп бирәбез, селкенми дә, күзләрен зур итеп ачып тик карап ята. Апасы мәктәптән кайткач, ул бәрәңгеләрне үзе ашап бетерә, бераз сөндесенә дә каптыра инде.

Көннәр тагын бертөрлегә әйләнде дигәндә, бу кызлар янына әтисе кайтып төште. Танкист икән, Уралга яңа танк алырга баруы. Арчада поездан төшеп калган да, җәяүләп, гаиләсенең хәлен белеп чыгарга булган. Солдат төнлә киткән иде инде.

Бу урында энекәшнең хәлен дә язып китик әле. Ул «р» хәрефен әйтә алмый иде. Төрлечә тырышып карады, «дуррак» сүзен әйткәндә генә, «р» авазы яхшы чыккач, шуны әйтергә күнегеп китте. Нәрсә әйтсәләр дә, «дурак» ди. Менә мин «р» хәрефен әйтә алам дип мактануы булгандыр, күрәсең. Ләкин шул сүз аркасында фаҗига чыга язды.

Эвакуацияләнгән өлкән кыз бер заман безнең авылны яманлый башлады. Монда пычрак, Мәскәүдә асфальт, ди. Энекәш җавап итеп тегe сүзне кабатлый. Кыз, Мәскәүдә Кремль бар, ди. Энекәш тагын тегe сүзне әйтә. Кыз: «Анда Сталин яши». Энекәш: «Дуррак...» Кыз ачуыннан киенеп чыгып китә.

Соңыннан гына белдек, мәктәпкә барып, укытучысына, мальчуган Сталин турында начар сүз әйтте, дип әләкләгән икән. Укытучы тиешле урынга җиткергән. Безнең әниләрне допроска чакырганнар. Башта кызларның әнисе кайтып керде. Кергән уңайга ук кызны тотып кыйный башлады. Тегe кыз, ычкынып китеп, өстәл астына кереп кача, әнисе өстерәп чыгарып, елый-елый дөмбәсли. Аннары безнең әни кайтып керде. Ул, өлкән бала булганга, мине кыйнарга тотынды. Тамагыбыз тук, өй җылы, нәрсә җитми сезгә дип, тукмый тына. Иртәгә сорау алырга мине чакырасылары икән. Шуннан рус хатыны минем алга тезләнеп елый-елый башымнан сыйпый, сөйләнә башлады. Тел белмибез бит, белгән кадәре ипи-тозлык та юк, аңлый алмый гаҗиз булып торам. Шунда әни, елама, минем малай сезгә каршы сүз әйтмәс, дип юатырга тырыша.

Мин аны бик күп еллар үткәч аңладым: бу гаилә бик зыялы, әмма системага яраклаша алмаган гаилә булган ул. Дөрес, миннән сорау алмадылар, күрәсең, эш зурга китми калгандыр. Ә курчак кебек матур кыз гаиләсе белән, көннәр җылыткач, каядыр китеп барды. Әтапка эләкмәгәннәрдер дип уйлыйсы килә. Безгә бик ямансу булып калды алардан соң. Энекәш тә «дурак» сүзен бүтән әйтмәде.

Нәсих ШӘЙХЕТДИНОВ.
Казан

КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТ

РФ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН КОНТРАКТ ТӨЗЕГӘЧ, БЕР ТАПКЫР ТҮЛӘНЕЛӘ:

195 000 сум

Махсус хәрби операциядә катнашкан өчен өстәмә түләүләр каралган

Хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итү өчен:

8 (843) 221-44-52



Ватан хакына

Анда бар да башкача...

Сабада яшәүче Рифат Рәшитов әнә шулай ди. Өлешчә мобилизация башлануга ук махсус хәрби операциягә киткән ир-егет туган ягына ялга кайтты. Тиздән кабат юлга кузгалачак. Китми калуны күз алдына да китерми. Анда иптәшләре көтә.

«Мондагы кеше андагы хәлләрне аңлаямачак. Хәер, кирәк тә түгел. Матур гына яшәгән тормышыбыз кинәт үзгәрер дип кем уйлаган инде? Әле ярый авыр чакта дуслар бар. Бер-беребездән җылы сүзне кызганмыйбыз. Гел янәшә булырга тырышабыз. Сугыш бит инде ул. Төрле чаклар да була. Әмма егетләрнең бердәм булуы коткара. Без, Сабадан бергә киткән егетләр, анда да янәшә генә яшибез. Шунысы җанга рәхәт. Үзеңнекеләр булганны белеп тору да җитә», – дип сөйли Рифат.

Махсус хәрби операция башланганчы, Рифатка тормышта күп кенә сынаулар белән очрашырга туры килә. Башта әтиләре дөнья куя, аннары әниләре бакыйлыкка күчә. Бу кайгы өч туганны тагын да берләштерә.

– Туганнарымны кайтып күрә алганыма шатмын. Әле бит тегендә үлем янәшә генә йөри. Бик куркыныч чаклар да бар. Шул чакларда догалар да укып куям. Җиңел булып китә. Никадәр авыр булса да, туган яктан килгән хәбәрләр яшәргә көч бирә. Шөкер, ризык җитәрлек. Киемнәр дә биреп торалар. Үзебез мунча ясап куйдык. Чиратлашып юынабыз. Хәзер инде пычрак вакытлар да бетте, салкын да түгел. Әмма күңел тынычлык көтә. Тиздән бар да бетәр дип өметләнәбез, – ди Рифат.

Егетләр туган яктан килгән хатларны яратып укый икән. Яшермиләр: күңелләренә иң якыны шулар.

– Балалар кулы белән язылган хатларны күз яшьләрсез укып та булмый. Шигырьләре дә күңелгә үтеп керә. Бер әйберне дә ташламыйбыз. Хатлар – түш кесәсендә, рәсемнәрне яшәгән урыннарга элеп куябыз. Рәхмәт ул сабыйларга, – ди Рифат. – Егет кеше куркып ятарга тиеш түгел инде ул. Илне сакларга кирәк икән, без анда булырга тиеш!

Шушы көннәрдә Сабага тагын бер төркем солдат кайтты. Алар арасында дустыбыз да бар иде. Егетләрне иртәнге өчтә каршы алырга бардык. Татарстан җибәргән автобус белән кайттылар. Туган туфракка аяк басуга, якыннары кочып алды аларны. Казанда яшәүче Ландышның ире кайткан. Ирен кочаклап елаган хатынны күрсәгез! Шатлык яшьләре булса да, күңелне тырный алар. Әнә тегендәрәк, йөргән егетен каршы алучы кыз басып тора. Шарлар күтәргән. Ә танышыбызны алып кайтырга дуслары Сабадан ук килгән. Илнар үзе дә баштарак югалып калды. Ә аннары әкренләп, күңелен бушатты.

– Әлегә без чикләрне саклыйбыз. Әмма барыбыз да белә: бүген син исән, икенче көнгә булмаска да мөмкинсең. Бердәм булуыбыз безне көчле итә. Ир кешеләр илне сакларга тиеш, – ди ул. – Сагынмаган кая? Әниемне, хатынымны, балаларымны өзелеп сагындым. Бу аерылышып тору мине бик үзгәртте. Бар нәрсәнең кыйммәтен аңладым хәзер. Йомшак урында ятып йоклауның, юынуның, тәмле ашларның монда кадере булмаган икән! Яшәү ямен, кадерен тоярга чит җирләрдә өйрәндем. Тормыш өйрәтә икән ул!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, хатыны

ГУСЕВА Людмила Игнатьевнаның

кинәт вафат булуы сәбәпле, өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Гусев Александр Петровичның авыр кайгысын уртаклаша.

ШЕЛТӘСЕЗ ТӘРБИЯ

Ата-аналар колагына

Россия күләмендә танылган гаилә психологы Александр Колмановский күптән түгел Казанга очрашуга килде. Ата-аналар, тәрбиячеләр, укытучылар арасында зур кызыксыну уяткан темага – балалар тәрбиясе турында сөйләде ул. Бәгырь җимешләрен сүгәргә ярыймы? Ничек итеп ике арада сәламәт мөнәсәбәтләр булдырырга? Белгеч шул һәм башка сорауларга җавап бирде.

Төрле карашлар

Гел сүгеп, шелтә белдереп тору балага кире йогынты ясамагае. Ягъни ул кылачак гамәлләре өчен алдан ук куркып торачак. Балага җәза биреп (физик җәза турында сүз бармый), без аны үзгәрергә, төзәлергә мәҗбүр итә алмыйбыз. Баланың гамәлләренә протест күрсәтү яңа протест тудыра. Бу үз чиратында киреләнү, ярсу хисләрен арттырачак. Җәзаның максаты – хатаны төзәтү түгел, ә куркыту, авырттыру, авырлык китерү.

Ата-аналар ни өчен баласына шелтә белдерергә ярата соң? Сәбәпләре нәрсә?

Кешенең табигате шундый: ул кем өчендер һәм үзе өчен курка. Кем өчендер курку – кайгырту, киңәш бирү кебек ул: «Башыңа ки, суык тимәсен», «Моны сатып алма, ул сиңа кирәк түгел» һәм башкалар. Үзең өчен курку – протест, каршы килү. «Син авырыячагыңны беләсеңме?», «Нәрсә сатып алганыңны аңлыйсыңмы син?» Ике төрле караш, сизелә бит? Һәр ата-анада да мондый куркулар бар, билгеле. Төп хикмәт – шушы куркуларның күләмендә.

Билгеле, баланың бүлмәсен җыештырмавы, тыңлаусыз булуы ачуны чыгара инде. Тик бу бит әле ата-анасы аны яратмый дигән сүз түгел. Мондый күренешләргә ачу килгән мизгелдә әти-әнидә иң элек үзе өчен курку уяна. Алар алга таба шул хискә нигезләнеп эш итә. Ни өчен үзләре өчен куркалармы? Баш миенә «Мин – начар әти, мин – начар әни, мин тәрбияли белмим» дигән уй кереп оялый чөнки. Бер мисал китерәм.

Психология белән мавыкканчы, музыка мәктәбендә белем бирдем. Шуннан бер хәл исемдә калган. Сәхнәдә бер бала фортепианода уйный. Бутала, ноталарга туры килми, кызарып чыга. Укучы өчен бөтенләй чит булган укытучы аны күз карашы белән тынычландырырга, булышып җибәрергә тырыша. Ә үзенең музыка укытучысы бу мизгелдә әлеге баланы үтерергә әзер! Аңлашыламы? Бер ситуациягә – ике төрле караш. Ягъни баланың ялгышулары укытучыны белгеч буларак кимсетә. Ата-аналар очрагында да шулай бит: баланың тәрбиясезлеге аларны тәрбияче буларак кимсетә.

Моннан тыш ата-аналар үз ата-анасының сүзеннән дә шүрли. Алар ни уйлар? Алар ни әйтер? Хәтта бу кешеләр инде фанилыкка күчкән булса да. Үгет-нәсыйхәт бирергә яраткан ата-анадан шундый ук ата-аналар үсеп җитә.

Әйтик, ике бала коридорда бер-берсенә бәрелешә, ди. Бер бала: «Гафу ит, мин сине күрмәдем», – ди. Икенчесе исә: «Кая чапканыңны карап йөр!» – дип кычкыра. Мондый аерма нәрсә белән аңлатыла? Гаепләүче бала үзенең гаебен танырга курка. Ул: «Миңа синең гафу сорауларың ник кирәк? Алданрак уйларга иде!» – дигән сүз ишетүдән шүрли. Хатаңны тану һәм шул хата өчен җәза алудан курку бу. Ә мондый куркулар, әйткәнебезчә, тормыштагы, көнкүрештәге даими үгет-нәсыйхәтләрдән туа. Баласына үгет укымаган ата-ана юк ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Туйга кадәр төзәлер

Баланың үз-үзен тотышына ике төрле реакция бар. Берсе «бала начар» дигән фикерне алга сөрсә, икенчесе – «балага кыен» дигәнне. Үзен имин һәм куркынычсыз мохиттә итеп тою бала өчен бик кадерле. Тагын бер мисал китерәм.

Коридор буенча бала йөгереп бара. Сөртенеп егыла, бәрелә, елый башлый. Аның янына бер өлкән кеше килә. Баланы кызганып: «Борчылма, елама, туйга кадәр төзәлер, әнә кара әле, нинди матур машина үтеп китте», – ди. Безнең уйлавыбызча, бу – әлбәттә, кызгану үрнәге, тынычландырырга тырышу. Ә бит бала башкача уйлый. «Ничек еламаска инде, авырта бит!» – ди ул. Димәк, аның хис-кичерешләре дөрес түгел булып чыгамы? Шуңа күрә дә ул тойганны аңларга тырышып, аның хәленә керергә кирәк. Бу очракта: «Сиңа ничек кыен икәнне аңлыйм, бүген сиңа уңыш елмаймаган», – диярга мөмкин иде. Бала үзен аңлауларын, ничек бар, шулай кабул итүләрен күрәчәк, бу инде андагы борчылу һәм агрессия дәрәҗәсен киметәчәк.

Балалар еш кына шаярырга, кыланырга, ә ата-аналар: «Алай эшләмә, кыланма!» – дип акыл өйрәтергә ярата. Бала бит бары тик үзенә игътибар итүләрен генә тели. Игътибар итеп, кылануларына карап куегыз да, бетте. Бала исә: «Игътибарыгыз өчен рәхмәт. Мин башка болай эшләмәм», – дип, уйга калачак.

Чикләмәскә

Ата-аналарга хисләрне тыю рәхәт түгел, билгеле. «Психосоматика» дигән төшенчә бар. Эмоцияләрне чыгармау чирләргә китерә. Лев Толстойның шундый сүзләре бар: «Концертта мин кымшанмыйча өч сәгать утыра алам. Әгәр дә берәрсе миңа: «Селкенмә», – ди икән, мин өч минут та утыра алмыйм». Хисләрне без тышкы факторлар кушканга гына тыярга тиеш түгел. Әгәр дә аңлы рәвештә тыеласыз икән, бу инде психосоматика түгел, бу – сайлау иреге.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН

Александр Колмановский – практик психолог, бала һәм ата-ана мөнәсәбәтләре буенча белгеч. Аның Беслан теракты корбаннары, онкологиядән интегүче балалар белән эшләү тәҗрибәсе бар.

Ничек әйтелә	Ничек әйтергә була
«Йә син машина каешын тагасың, йә мин сине үзем белән башка беркая да алып бармыйм!»	«Балам, каеш эләктерергә теләмәгәнеңне аңлыйм, ләкин моны эшләргә кирәк, югыйсә безгә штраф салачаклар, без башка беркая да йөри алмаячакбыз».
«Кылануларыңны туктат!»	«Син бигрәк артист инде безнең».
«Булды, җитте, уйнамыйсың!»	«Мин дә күпме телим, шулкадәр уйнар идем, әмма инде уенны туктатырга вакыт җиткән».

КОТКАРУЧЫ МАРАТ ӘХМӘТВӘЛИЕВ:

«КЕШЕСЕ ДӘ, ХАЙВАНЫ ДА КЫЗГАНЫЧ»

Марат Әхмәтвәлиевнең шәхси архивыннан

«Коткаргач, күңелдә горурлык хисе уяна, ә менә коткара алмау бик аяныч», – ди Марат Әхмәтвәлиев.

Саба егете Марат Әхмәтвәлиев бу көннәрдә Кама елгасы буенда кизү тора. Коткаручы ул. Көзен боз катканда, язын ташу вакытында аларның отрядын Алексеевск бистәсенә кизү торырга җибәрәләр икән. Аның белән судагы иминлек, балыкчылар, башкарган хезмәте, батырлык турында сөйләштек.

Маратларның отряды Шәмәрдән бистәсендә урнашкан. Аларның карамагында – Саба, Кукмара, Балтач, Арча, Теләче районнары. Кирәк вакытта башка районнарга юллыйлар. Кама буенда вагонда яши алар. Бер атнадан икенче төркем киләчәк. Ул-бу килеп чыкса, шунда ук ярдәмгә ашыгалар. Өсләрендә – махсус кием. Кулларында – суда да, бозда да йөри торган махсус техника һәм коткару җайланмалары. Куркуга урын юк, шулай батыр булырга иязлэнгән инде алар.

– Быел яз иртә һәм тиз килде. Боз бар әле: яр буена килеп бәреләләр дә кире китәләр. Балыкчылар әлегә күренми. Безгә кадәр килгән коткаручылар ике балыкчыны коткарган, – дип сөйли 43 яшьлек Марат Әхмәтвәлиев.

Кизү торуның төп сәбәбе дә балыкчыларга күз-колак булу. Коткаручылар аларга иминлек кагыйдәләре турында белешмәләр тарата, кирәк икән, кисәтү дә ясыйлар. Марат Әхмәтвәлиев узган көз ике балыкчының гомерен саклап калган. Аларга кисәтү ясап йөргәндә, берсе күз алдында суга төшеп киткән. Бәхеткә, кулында көрәге, коткару кирәк-яраклары булган. Тиз генә боз өстеннән шуышып, балыкчыга таякны сузып, тартып чыгарган.

– Өсләрендә – калын кием, аякларында – резин итек, аның эченә су тиз тула. Кием үзеннән-үзе суга батыра. Боз өстенә чыгу бик авыр. Юеш булгач, кул тая. Чыгып котыласың икән, бозга басмыйча, килгән ягыңа таба шуышып китү сорала. Юеш киемнәреңне салып, коткаручылар чакыртырга кирәк, – дип киңәш итә ул. – Яз көне кайберәүләр карда йөри торган техника белән боз астына төшеп китә. Балыкчылар арасында үлүчеләр дә аз түгел.

Азартка бирелеп, үз гомерләре турында уйламыйлар, дип балыкчыларны да сүгеп алды Марат.

– Кемдер гомер буе балыкка йөрим, берни булмый, дип бозга ышанып керә. Тик иртә белән боз өсте нык булып тоелса да, көндез кояш нурларында икенче хәлгә керә. Менә шуңа баталар да инде. Яшь балыкчыларга тәҗрибә җитми. Алар агым булган җирдә бозның юка булуын белми. Күп һәм зур балыкка кызыгып, тормышларын куркыныч астына куялар. Гомерне балыкка алыштырып булмый. Аны сакларга кирәк. Балык бетми, аны җәй көне дә тотарга мөмкин. Балыкка йөргәндә, кагыйдәләрне истән чыгарырга ярамый, – ди ул.

Балыкчылар, суга батучыларны коткару белән генә эшләре бетми. Юл-транспорт һәлакәте булган урыннарга барып, зыян күрүчеләргә ярдәм итәләр. Анда кан, ыңгырашкан, кычкырышкан тавышлар... Тимер юлда булган фаҗигаләр бик аянычлы. Янгын сүндерүчеләргә булышырга да чакыргалыйлар икән. Фатир ишекләре, тәрәзәләр ябылганда да алар кирәк. Газларын ачып калдырган, шулай ук егылып, аңын югалткан өлкәннәр дә, фатир эчендә бикләнеп калган балалар да очрый. Ишектән керә алмаган очракта күпкатлы йортларның түбәсеннән төшеп, бәладән коткаралар. Көз көне югалган гөмбәчеләрне эзләп, урманнарга баралар. Җәй көне мәктәп, балалар бакчалары, лагерьларга еланнар кергәли. Эт-мәчеләр, пошиларның тирән чокырга төшеп киткән чаклары да булгалый. Бармагындагы йөзеген сала алмаган хатыннар да ярдәм сорап килгәли. Кыскасы, кемнәр генә мөрәҗәгать итми.

Заманасында вузда тарих укытучысы белгечлегенә укыган егет бүген кешеләргә ярдәм итеп, аларны бәла-казадан коткарып, тормышта ямь таба. Башта янгын сүндерүче, аннан ун ел кинолог булып эшләгән. Дүрт аяклы дусты белән бергәләп югалган кешеләрне табарга булышкан. Коткару-эзләү отрядына килүенә – 15 ел.

– Кеше коткару – безнең төп эшебез. Коткардык, батырлык эшләдек, дип кычкырып йөрмибез. Болай мактанып йөрү килешми. Коткарабыз да онытабыз, дигәндәй. Булыша алгач, сөенәсең инде, эчтән генә горурлык хисе яна. Кеше гомере бит ул! Коткара алмасаң, аянычлы менә. Ул чакта төннәрен дә борчылып ятасың әле. Курку белмәс кебек тоелсак та, йөрәгебез нечкә безнең. Кешесе дә, хайваны да – барысы да кызганыч, – ди Марат Әхмәтвәлиев.

Марат әйтүенчә, теләсә кем коткаручы булып эшли алмый. Беренчедән, физик һәм психик яктан нык булу кирәк, икенчедән, коткыга бирелергә ярамый. Өч ел саен белемнәрен яңартып, имтихан тапшырырга туры килә икән.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 247

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+